Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Елаур торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ

11 ноябрь 2020 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге Елаур торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслегеен күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре).
Октябрь т.п. су алу өчен пирс әзерләү ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
Елаур торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы: О.В.Охотникова